РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**14.10.2024** Кукмара ш. **№ 577**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт турында

1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә «Җирләү һәм җирләү эше турында", «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирлекләре башкарма комитетларының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турындагы килешүләрне гамәлгә ашыру максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә җирләү мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеген вәкаләтне гамәлгә ашыру өчен җаваплы итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка җиткерелгән көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Ч.Г. Хәнәфина**

Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручының
14.10.2024 елның 577 номерлы
карары белән расланган

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә җирләү мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе

Әлеге Тәртип «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә җирләү мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында эшләнде.

1 бүлек Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә җирләү мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт буларак Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – махсуслаштырылган хезмәт) эш итә. Махсуслаштырылган хезмәт җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеген түләүсез нигездә күрсәтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

Махсуслаштырылган хезмәт үз эшчәнлегендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының муниципаль хокукый актларына, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2024 елның 01 апрелендәге 64/0 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында зиратларны төзекләндерү һәм карап тоту, җирләү эшен оештыру буенча методик тәкъдимнәргә, әлеге Тәртипкә таяна.

1.2. Махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан җирләү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының муниципаль акты белән раслана.

1.3. Махсуслаштырылган хезмәт җирләү буенча җирләү буенча исемлектәге гарантияләнгән хезмәтләрне күрсәтү кысаларындагы эшләрне башкару өчен физик яки юридик затлар белән контрактлар (шартнамәләр) төзи.

## 2 бүлек Махсуслаштырылган хезмәтнең төп функцияләре һәм бурычлары

2.1. Җирләү эше өлкәсендә вәкаләтләрнең бер өлешен район дәрәҗәсенә тапшыру турында килешүләр төзелгән җирлекләрнең җәмәгать зиратларында махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан җирләү буенча түбәндәге хезмәтләр исемлеге түләүсез нигездә күрсәтелә:

1) җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү;

2) җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү;

3) мәрхүмнең гәүдәсен (мәетен) зиратка илтү;

4) күмү.

2.2. Ире (хатыны), якын туганнары, башка туганнары йә мәрхүмнең законлы вәкиле булмаганда яисә алар тарафыннан җирләү мөмкинлеге булмаганда, шулай ук җирләү бурычын үз өстенә алган башка затлар булмаганда, өендә, урамда яисә башка җирдә үлгән кешене җирләү, Эчке эшләр органнары аның шәхесен ачыклаганнан соң, махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, үлем сәбәбе ачыкланганнан соң өч тәүлек эчендә гамәлгә ашырыла.

2.3. Шәхесе Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокларда Эчке эшләр органнары тарафыннан билгеләнмәгән үлгәннәрне җирләү күрсәтелгән органнарның ризалыгы белән махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан мондый очраклар өчен билгеләнгән җәмәгать зиратлары кишәрлекләрендә җиргә иңдерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.4. Әлеге Тәртипнең 2.2 һәм 2.3 пунктларында күрсәтелгән мәетләрне җирләгәндә, махсуслаштырылган хезмәт күрсәтүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү;

2) кәфенләү (киендерү);

3) табут бирү;

4) үлгән кешене зиратка алып бару;

5) күмү.

2.5. Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген күрсәтү махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда гамәлгә ашырыла.

## 3 бүлек Махсуслаштырылган хезмәт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга таләпләр

3.1. Махсуслаштырылган хезмәт Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм җирләү һәм җирләү эше өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләрен үтәргә тиеш, шул исәптән:

- түләүсез нигездә күмү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре;

- җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә керә торган хезмәтләр күрсәтү сыйфатына таләпләр.

3.2. Махсуслаштырылган хезмәтнең гарантияләнгән хезмәтләр исемлеген күрсәтүдән кирәкле чаралар булмау сәбәпле яисә башка нигезләр буенча баш тартуы рөхсәт ителми.

3.3. Махсуслаштырылган хезмәтнең хокукы юк:

1) мәрхүмнең теләге буенча, шулай ук мәрхүмнең ире (хатыны) исеменнән, якын туганнары, башка туганнары, законлы вәкилләре, мәрхүмне җирләү бурычын үз өстенә алган башка затлар исеменнән һәм кушуы буенча эш итүче затларга күмүне (шул исәптән мәрхүмне җиргә иңдерү юлы белән) гамәлгә ашыруда каршылык күрсәтергә;

2) махсуслаштырылган хезмәттән ритуаль хезмәтләр, шул исәптән түләүле нигездә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә керә торган хезмәтләр сатып алырга мәҗбүр итәргә (ирексезләп кушарга).

## 4 бүлек Махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибенә төп таләпләр

4.1. Махсуслаштырылган хезмәт җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерә, гореф-гадәтләргә, шулай ук үлгән кешенең диненә туры китереп, җирләү датасын һәм вакытын билгели.

Документларны рәсмиләштерү нәтиҗәләре буенча махсуслаштырылган хезмәт әлеге Тәртипнең 2 бүлеге нигезендә җирләү буенча хезмәт күрсәтә.

4.2. Махсуслаштырылган хезмәт консультатив ярдәм күрсәтә:

җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеген күрсәтү тәртибе буенча;

зиратларның эш кагыйдәләре буенча;

җирләү һәм җирләү эше өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә гражданнарга җирләүгә социаль пособие һәм бер мәртәбә бирелә торган матди ярдәм бирү тәртибе һәм күләмнәре буенча.

4.3. Махсуслаштырылган хезмәт бинасында яхшы күренә торган урында түбәндәге мәҗбүри мәгълүмат булырга тиеш:

1) «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

2) «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон;

3)
«Вафат булганнарны күмү буенча гражданнарның хокуклары гарантияләре турында» Россия Федерациясе Президентының 1996 елның 29 июнендәге 1001 номерлы Указы;

4) җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге.

## 5 бүлек Махсуслаштырылган хезмәтнең җаваплылыгы

Җирләү һәм җирләү эше өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен махсуслаштырылган хезмәт гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы.